ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.07. 2020 ел Баулы шәһәре №147

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы «Административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафлар буенча бурычны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» карарына (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 2 июлендәге нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү хакында» 975 номерлы карары нигезендә Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 15 мартындагы 67 номерлы «Административ комиссия тарафыннан салынган административ штрафлар буенча бурычны Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы бюджетына түләтү өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында» карарына (2020 елның 24 апрелендәге 88 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

III бүлектә д) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) җирле бюджетка түләүләр буенча бурыч түләүне өметсез дип тану очракларын раслый торган документлар, шул исәптән:

физик затның - җирле бюджетка түләүләр түләүченең үлүен раслый торган яисә аны вафат дип игълан итү фактын раслый торган документ;

конкурс производствосын тәмамлау яисә шәхси эшкуар булган гражданның – җирле бюджетка түләү түләүченең мөлкәтен сатуны тәгәлләү турында суд акты, шулай ук эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан индивидуаль эшкуар булган физик затның – җирле бюджетына түләүләрне түләүченең эшмәкәр буларак эшчәнлеген туктату турында белешмәләр (аны бөлгенлеккә төшү (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә);

конкурс производствосын тәмамлау яисә гражданның - җирле бюджетка түләүләрне түләүченең мөлкәтен сатуны тәгәлләү турында суд акты;

оешма - җирле бюджетка түләүләрне түләүче ябылуга бәйле рәвештә эшчәнлекне туктату турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ;

юридик затны – җирле бюджетка түләү түләүчене теркәүче орган карары буенча күрсәтелгән реестрдан төшереп калдыру турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр булган документ;

штраф яки суд акты рәвешендә җәзага тартылганнарга карата амнистия турында яки кичерү турында акт, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы җирле бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта;

«Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1нче өлешенең 3нче яисә 4нче пунктында каралган нигездә башкарма документ алучысына кайтарылуга бәйле рәвештә башкару производствосын тәмамлау турында суд приставы-башкаручы карары;

бурычлыны бөлгенлеккә төшү (банкрот) дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча җитештерүне туктату турындагы гаризаны кире кайтару турындагы яки банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмау сәбәпле эш туктатылу турында суд акты;

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров